РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел « 30 » апрель №268

«2019-2021 елларга Ютазы муниципаль районында спорт һәм физик культураны үстерү» муниципаль программасында каралган спорт чараларын үткәрүгә бүлеп бирелгән җирле бюджет акчаларын тоту тәртибен» раслау турында

Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының Физик культура-савыктыру һәм спорт чараларының календарь планына кертелгән физкультура-савыктыру, спорт һәм тренировка чараларын үткәрүгә чыгымнар нормативларын раслау турында» 2015 елның 18 мартындагы 160 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 21 сентябрендәге 868 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советының 2015 елның 11 сентябрендәге 43 санлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2006 елның 12 гыйнварындагы 1 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә, «2019-2021 елларга Ютазы муниципаль районында спорт һәм физик культура төрләрен үстерү» муниципаль программасында каралган спорт чараларын җирле бюджет акчалары хисабына финанслау тәртибен билгеләү максатларында Татарстан Республикасы Ютазы муниипал районы башкарма комитеты к а р а р и т ә:

1. Кушымта нигезендә «Ютазы муниципаль районында 2019-2021 елларга спорт һәм физик культура төрләрен үстерү»

муниципаль программасында каралган спорт чараларын үткәрүгә бүлеп бирелгән җирле бюджет акчаларын тоту» тәртибен раслау

2. Әлеге карарны «Ютазы таңы» («Ютазинская новь») газетасында бастырып чыгарырга һәм http://jutaza.tatarstan.ru электрон адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С. А. Рузановка йөкләргә.

Җитәкче А. А. Шафигуллин

2020 елның 30 апреленнән
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
башкарма комитеты
җитәкчесе
карарына финанслауның
268 санлы карарына кушымта

**«2019-2021 елларга Ютазы муниципаль районында спорт һәм физик культура төрләрен үстерү» муниципаль программасында каралган спорт чараларын үткәрүгә бүлеп бирелгән җирле бюджет акчаларын тоту тәртибен раслау турында**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «2019-2021 елларга Ютазы муниципаль районында спорт һәм физик культураны
төрләрен үстерү» муниципаль программасында каралган спорт
үстерү» муниципаль программасында каралган спорт чараларын үткәрүгә бүлеп бирелгән җирле бюджет акчаларын (алга таба - тәртип) Ютазы муниципаль районы акчаларын (алга таба - җирле бюджет акчалары) финанс белән тәэмин итүне регламентлый.
муниципаль районы акчаларын (алга таба - җирле бюджет акчалары) финанс белән тәэмин итүне регламентлый.

1.2. Спорт чараларын уздыру җирле бюджетта каралган бюджет йөкләмәләре кысаларында гамәлгә ашырыла.

1.3. «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге» МКУ ведомствосы буйсынуындагы учреждениеләр һәр спорт чарасына чыгымнарның проект сметаларын төзи, йә агымдагы айга эш планы нигезендә, агымдагы елга расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә, аларны максатчан файдалануны «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге» МКУ карамагындагы учреждениеләр аша тормышка ашыра

1.4. Спорт чараларын үткәрүгә акча тотуны «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге» МКУ буйсынуындагы учреждениеләр «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге» МКУ ведомствосындагы учреждениеләрнең сметасы һәм боерыклары нигезендә тормышка ашыра

1.5. «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге» МКУга буйсынучы учреждениеләр Ютазы муниципаль районы

администрациясенең «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль бюджет учреждениесенә тәкъдим итәләр:

- Бөтенроссия, халыкара дәрәҗәдәге ярышларга рәсми чакыру;
- спорт чарасын үткәрү турында нигезләмә ярышларга рәсми чакыру булырга мөмкин);
- һәр спорт чараларына чыгымнар сметасы;
- исәп-хисап счетлары, килешүләр, башкарылган эшләрнең актлары;
- бюджет акчаларын тоту турында аванс хисабы, ул үз эченә алган чыгымнарны раслый торган документлар, гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә ай саен бирелә.

1.6. Әлеге тәртиптә спорт чараларын үткәрүгә чыгым нормалары билгеләнә (№1,2,3,4 кушымталар).

1.7. Балалар, укучы яшьләр һәм халыкның төрле яшь төркемнәре арасында физкультура-спорт чараларын уздыру кагыйдәләре һәм финанс шартлары ярышлар турында нигезләмәләрдә билгеләнә (шул исәптән, спорт чаралары һәм ярышлар турында өлкә, төбәкара һәм бөтенроссия федерацияләре тарафыннан үткәрелә торган чаралар һәм ярышлар турындагы нигезләмәләрдә һәм регламентларда).

1.8. Спорт чараларын үткәргәндә, «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге МКУ» карамагындагы учреждениенең боерыклары нигезендә, спорт чараларында катнашучыларның саны, урыны, аларны үткәрү вакыты һәм кушымталарда билгеләнгән спорт чараларында катнашучыларны матди тәэмин итү нормалары раслана.

1.9. Хөкемдарлар коллегияләренең (бригадаларының) саны спорт төрләре буенча ярышлар кагыйдәләре нигезендә билгеләнә.

1.10. Физкультура чарасында һәм спорт чарасында катнашучылар исемлегенә кермәгән җәлеп ителгән белгечләр һәм хезмәт күрсәтүче персоналның хезмәт өчен түләү чыгымнары чараны үткәрүгә расланган смета кысаларында төзелгән килешүләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 2. Ютазы муниципаль районы территориясендә үткәрелә торган физкультура һәм спорт чараларын карарынафинанслау

2.1. Җирле бюджет акчалары хисабына түбәндәге чыгымнар үткәрелергә мөмкин:

- төзелгән шартнамәләр нигезендә физик затларга (судьяларга, техник персоналга эшләр (хезмәт күрсәтүләр) башкарган өчен түләү (1 нче кушымта);

- ярышларда катнашучыларның туклануын һәм (яки) яшәү өчен түләү (2 нче кушымта);

- спорт ярышларында җиңүчеләрне һәм призерларны бүләкләү өчен истәлекле бүләкләр, кубоклар, медальләр, дипломнар, грамоталар, чәчәкләр сатып алу (3 нче кушымта);

- канцелярия кирәк-яраклары һәм чыгым материаллары сатып алу (4 нче кушымта);

2.2. Физкультура чараларын һәм спорт чараларын ачу һәм ябу тантаналарын уздыруга, спорт мәгълүмати-техник тәэмин ителешенә бәйле чыгымнар каплана.

## 3. Ютазы муниципаль районыннан читтә үткәрелә торган өлкә, төбәкара, Бөтенроссия физкультура чараларында һәм спорт чараларында катнашуны финанслау карарынафинанслау

3.1. Җирле бюджет акчалары хисабына ярышларда катнашу һәм укыту-тренировка җыеннары узу өчен командировкага җибәрелә торган Ютазы муниципаль районы җыелма командалары спортчыларына, тренерларына һәм белгечләренә карата чыгымнар каплана.

3.2. Җирле бюджет акчалары исәбеннән ярышларда катнашучыларның, тренерларның ярышлар уздырыла торган урыннарга кадәр һәм киресенчә, урнашу, спортчыларны мәҗбүри иминләштерүгә бәйле чыгымнар, ярышлар уздыру турындагы нигезләмә таләпләренә туры китереп, ярышлар уздыру өчен взнослар түләү, спорт корылмалары, транспорт чаралары, махсус техника һәм җиһазлар өчен түләү чыгымнары каплана. Спортчыларны, тренерларны һәм белгечләрне физкультура чараларын һәм спорт чараларын үткәргәндә туклану белән тәэмин итү 2 кушымта белән билгеләнгән чыгымнар нормаларына туры китереп башкарыла.

1.3. Җирле бюджет акчалары исәбеннән укыту-тренировка җыеннарын оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнар 2, 4 нче кушымталар буенча билгеләнгән нормалар нигезендә каплана.

**«2019-2021 елларда**
**Ютазы муниципаль районында**
**спорт һәм физик культура төрләрен үстерү»**
**муниципаль программасында каралган**
**спорт чараларын үткәрүгә бүлеп**
**бирелгән җирле бюджет акчаларын**
**тоту тәртибен раслау турындагы боерыкка**
**2 кушымта**

Физкультура чараларына хезмәт күрсәтү өчен
(хөкемдарларга һәм техник персоналга)
физик затларга түләү өчен чыгымнар нормалары
чыгымнары нормалары

| п/п | Хөкемдарлар вазыйфаларының атамасы | Хөкемдарлар категорияләрен исәпкә алып, түләүләр күләме, сумнарда | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | МК, ВК | 1К | 2К | 3К / Ю / С | категориясез |
| 1. | Баш хөкемдар | 745 | 30 | - | - | - |
| 2. | Баш хөкемдар-сәркатип | 745 | 30 | - | - | - |
| 3. | Баш хөкемдар, баш сәркатип урынбасары | 685 | 70 | 455 | - | - |
| 4. | Хөкемдарлар | 640 | 10 | 435 | 400 | 340 |
| Команда уен төрләре | | | | | | |
| 5. | Уенның баш хөкемдары | 435 | 00 | - | - | - |
| 6. | Баш судья һәм уен ярдәмчесе | 365 | 40 | - | - | - |
| 7. | Инспекторлар (техник делегат, комиссар) | 435 | - | - | - | - |
| 8. | Судьялар (бригада составында) | 330 | 10 | 285 | 260 | 230 |

**«2019-2021 елларда**
**Ютазы муниципаль районында**
**спорт һәм физик культура төрләрен үстерү»**
**муниципаль программасында каралган**
**спорт чараларын үткәрүгә бүлеп**
**бирелгән җирле бюджет акчаларын**
**тоту тәртибен раслау турындагы боерыкка**
**2 кушымта**

Физкультура чараларын һәм спорт чараларын үткәргәндә спортчыларны,
тренерларны һәм белгечләрне туклындыруны тәэмин итү чыгымнары нормалары

| п/п | Спорт чараларының исеме | Бер кешегә бер айга чыгымнар нормасы, сумнарда |
|---|---|---|
| 1. | Массакүләм физкультура-спорт ярышлары һәм чаралар | 365 кадәр |
| 2. | Татарстан Республикасы чемпионатлары, беренчелекләре, кубоклары һәм аларга әзерләнү чаралары (спартакиадалар, универсиада) | 425 кадәр |
| 3. | Бөтенроссия ярышлары һәм аларга әзерләнү чаралары | 730 кадәр |

Спортчыларны, тренерларны һәм физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм тренировка чараларында катнашучыларны яшәү белән тәэмин итү чыгымнары нормалары

| п/п | Яшәү өчен торак пунктлар категорияләре исеме | Бер кешегә көнлек бәя, сум |
|---|---|---|
| 1. | Мәскәү, Санкт-Петербург, Сочи шәһәрләре | 1120 кадәр |
| 2. | Россия Федерациясенең административ үзәк субъектлары;<br>Ерак Төньяк территориясенә кертелгән шәһәрләр, торак пунктлар | 910 - 1120 |
| 3. | Россия Федерациясе территориясенең башка шәһәрләре һәм торак пунктлары | 670 - 850 |

**«2019-2021 елларда**
**Ютазы муниципаль районында**
**спорт һәм физик культура төрләрен үстерү»**
**муниципаль программасында каралган**
**спорт чараларын үткәрүгә бүлеп**
**бирелгән җирле бюджет акчаларын**
**тоту тәртибен раслау турындагы боерыкка**
**2 кушымта**

**Спорт ярышларында җиңүчеләрне һәм призерларны бүләкләү өчен истәлекле**
**бүләкләр алу өчен чыгым нормалары**

| **Физкультура һәм спорт чараларының исемлеге** | **Бүләкләрнең хакы (сумнарда)** | |
|---|---|---|
| Сайлап алу, зона, финал район ярышлары | Команда | Шәхси |
| 1 урын | 4000,00 кадәр | 1000,00 кадәр |
| 2 урын | 2500,00 кадәр | 750,00 кадәр |
| 3 урын | 1500,00 кадәр | 500,00 кадәр |

**Искәрмә:**

1. Акчалата, истәлекле бүләкләрнең эквивалент бәясен бүләкләү сыйфатында бирү тыела.
2. Спортның уен төрләрендә һәм команда дисциплиналарында призлы урыннар алган командалар кубоклар, ә командаларда катнашучылар - медальләр, дипломнар яки грамоталар белән бүләкләнә (ярышлар үткәрү турында нигезләмәдә каралса).

**«2019-2021 елларда**
**Ютазы муниципаль районында**
**спорт һәм физик культура төрләрен үстерү»**
**муниципаль программасында каралган**
**спорт чараларын үткәрүгә бүлеп**
**бирелгән җирле бюджет акчаларын**
**тоту тәртибен раслау турындагы боерыкка**
**2 кушымта**

**Канцелярия товарлары һәм чыгым материаллары сатып алуга чыгым нормалары**

| **Спорт чараларыны исемлеге** | **Бер кешегә көнлек чыгымнар (сумнарда)** |
|---|---|
| Район ярышлары | 50, 00 кадәр |
| Ютазы муниципаль районы территориясендә үткәрелә торган төбәкара ярышлар, республика ярышлары (сайлап алу, зона, финал) | 50, 00 кадәр |
| Ютазы муниципаль районы территориясендә уза торган Бөтенроссия ярышлары | 70, 00 кадәр |
| Укыту-тренировка җыеннары | 50, 00 кадәр |